ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 1 өлештә:

“(алга таба – урын милекчесе)” сүзләрен (“алга таба шулай ук – урын милекчесе)” сүзләренә алмаштырырга;

“һәм аңа ремонт” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 өлештә “Урыннар” сүзе алдыннан “Әлеге статьяның $4^1$ өлешендә билгеләнгән очрактан тыш,” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

“$4^1$. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә кертелгән һәм аны актуальләштергәндә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелгән күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы шушы күпфатирлы йорт кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап биш календарь ай үткәннән соң барлыкка килә. Капиталь ремонт фонды булдыру алымын билгеләү турында карар урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы барлыкка килгәнче өч айдан да соңга калмыйча кабул ителергә һәм гамәлгә ашырылырга тиеш.”;

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәт объектларын файдалануга бирүдән керемнәр, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы акчалары, шул исәптән торак милекчеләре ширкәтенең, торак кооперативының хуҗалык эшчәнлегеннән алынган керемнәр, Россия Федерациясе Торак кодексы, торак милекчеләре ширкәте уставы, торак кооперативы уставы нигезендә кабул ителгән урыннар милекчеләре карары, торак милекчеләре ширкәте әгъзалары карары, торак кооперативы әгъзалары карары буенча урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычын үтәү исәбенә капиталь ремонт фонды булдыруга һәм (яисә), капиталь ремонт өчен кертемнең билгеләнгән минималь күләменнән чыгып, булдырыла торган капиталь ремонт фонды өлешенә өстәп капиталь ремонт фонды өлешен булдыруга юнәлдерелергә мөмкин, ул күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча теләсә кайсы хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне финанслау өчен тотылырга мөмкин.”;

д) 9 өлештә:

1 пунктта “, әгәр бу йортлар дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрындагы документлар нигезендә уртак чиге булган һәм үз чикләрендә шушы йортлардагы урыннар милекчеләренең бергәләшеп файдалану өчен билгеләнгән инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре, инфраструктураның башка элементлары булган җир кишәрлекләрендә урнашкан булса” сүзләрен “Россия Федерациясе Торак кодексының 136 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә” сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта “яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы” сүзләрен төшереп калдырырга;

$2^1$ пунктта “идарә итүче оешма” сүзләре алдыннан “күпфатирлы йортка идарә итүне идарә итү шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашыручы” сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлештә:

5 пунктта “(еллык)” сүзен төшереп калдырырга, “күпфатирлы йортларда” сүзләре алдыннан “өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,” сүзләрен өстәргә;

6 пунктта “(еллык)” сүзен төшереп калдырырга, “күпфатирлы йортларда” сүзләре алдыннан “өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,” сүзләрен өстәргә;

11 пунктта “капиталь ремонт фонды” сүзләре алдыннан “әлеге Законның 2 статьясындагы $4^1$ өлешендә билгеләнгән очрактан тыш,” сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $13^3$ пункт өстәргә:

“$13^3$) капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында, счетларында булдырган очракта региональ оператор тарафыннан яисә капиталь ремонт фондын махсус счетта булдырган очракта махсус счет хуҗасы тарафыннан, капиталь ремонт фонды булдыру алымы үзгәргәндә, тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яисә) региональ операторга капиталь ремонт фонды булдыруга бәйле булган барлык документларны һәм мәгълүматны тапшыру тәртибен билгеләү;”;

б) 2 өлешнең 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4 статьяның 1 пунктында “(еллык)” сүзен төшереп калдырырга, “тиешле” сүзе алдыннан “өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,” сүзләрен өстәргә;

4) 5 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Региональ оператор күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада каралган күләмдә һәм срокларда урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдыра торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны һәм аны финанслауны, шул исәптән капиталь ремонт фонды акчалары җитмәгән очракта, капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган башка күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең түләүләре исәбеннән алынган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) җирле бюджеттан алынган субсидияләр исәбеннән, закон белән тыелмаган башка акчалар исәбеннән тәэмин итә.”;

б) 6 өлештә “гомуми мөлкәткә” сүзләреннән соң “капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә)” сүзләрен, “бюджет” сүзеннән соң “һәм казна” сүзләрен өстәргә;

в) $6^2$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$6^2$. Региональ оператор Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органында счетлар, махсус счетлардан тыш, ачарга хокуклы. Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка очракларда региональ оператор тарафыннан счетлар, махсус счетлар ачу Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурс нәтиҗәләре буенча региональ оператор тарафыннан сайлап алынган Россия кредит оешмаларында гамәлгә ашырыла. Мондый конкурс уздыру тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.”;

5) 6 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Региональ операторның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны финанслауга ел саен тоту хокукы булган акчалар күләме (гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт киләсе чорда ясалырга тиешле күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан булдырылган капиталь ремонт фондлары акчалары исәбеннән бирелә торган акчалар күләме) региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменә һәм (яисә) агымдагы елда капиталь ремонт өчен кертемнәр керүнең фаразлана торган күләменә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән өлешнең күләме, региональ оператор тарафыннан алдагы чорда тотылмаган калган акчаларны исәпкә алып, региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән 92 процентны тәшкил итә.”;

6) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктта “, лифтларны диспетчерлаштыру системасы белән җиһазлау” сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

“13) күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү.”;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срогы җиткәнче шушы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада каралган аерым хезмәтләр күрсәтелгән һәм (яисә) аерым эшләр башкарылган булса, бу хезмәт күрсәтүләргә һәм (яисә) эшләргә түләү бюджет акчаларыннан һәм региональ оператор акчаларыннан файдаланмыйча гына гамәлгә ашырылган булса һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә әлеге хезмәтләрне яңадан күрсәтү һәм (яисә) эшләрне яңадан эшләү күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта таләп ителмәсә, шушы хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең хакына тигез булган, әмма әлеге хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр хакының Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменнән артык булмаган күләмдәге акчалар капиталь ремонт фондларын булдыручы урыннар милекчеләренең региональ оператор счетына, счетларына капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен киләчәк чорга үтәү исәбенә кертеләләр.”;

7) 10 статьяда:

а) 4 өлештә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан (шул исәптән барлык биналары бер милекчегә караган күпфатирлы йортлар) һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган муниципаль адреслы программаларга кертелгән барлык күпфатирлы йортлар исемлеге, моңа Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлар керми;”;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның план чоры, шул исәптән хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең һәр төре буенча башкару сроклары, шул ук вакытта күрсәтелгән срок календарь елны яисә мондый ремонт ясалырга тиешле өч календарь елдан артып китмәгән чорны күрсәтеп билгеләнергә мөмкин;”

б) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Капиталь ремонт буенча региональ программага күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның билгеләнгән срогын соңрак чорга күчерүне, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төре исемлеген кыскартуны күздә тота торган үзгәрешләр кертү урыннар милекчеләре гомуми җыелышының тиешле карары булганда гамәлгә ашырыла, аңа түбәндәге очраклар керми:

1) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырылган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төренең исемлеген кыскарту капиталь ремонт үткәрелергә тиешле конструктив элементларның булмавына бәйле булса;

2) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләре алданрак үткәрелгән булса һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә яңадан мондый хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта таләп ителми дип табылса;

3) капиталь ремонт фонды булдыру ысулын үзгәртү Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясының 7 өлешендә каралган нигезләрдә башкарылса. Бу очракта капиталь ремонт ясау вакыты күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә ачыклана.”;

в) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ өлеш өстәргә:

“$10^1$. Капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кертү турындагы карарлар торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы раслаган методик тәкъдимнәр нигезендә кабул ителә.”;

г) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрен төгәлләштерү, капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, өч еллык срок кысаларында елларга бүлеп, күрсәтелгән срокка расларга тиеш. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына әлеге статьяның 10 өлешендә каралган нигезләрдә үзгәрешләр кертелгәндә, урыннар милекчеләре белән килештерү таләп ителми.”;

д) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәргә:

“$11^1$. Җирле үзидарә органнары капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын, Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, өч еллык срок кысаларында елларга бүлеп, күрсәтелгән срокка расларга тиеш.";

8) 12 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

9) 13 статьяның 2 өлешендә "яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына" сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка сроклар билгеләнгән нигезләмәләрдән кала, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының "б" пунктчасы нигезләмәсе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле акты үз көченә кергән көннән соң 90 көн узгач кулланыла. Күрсәтелгән срокка кадәр региональ операторның, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда, җирле үзидарә органнарының, муниципаль бюджет учреждениеләренең күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр өчен һәм (яисә) эшләр башкару өчен подряд оешмаларын җәлеп итү тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

3. "Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында" 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) 5 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезләмәләре, региональ операторлар тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясының 2 өлеше таләпләренә туры килә торган Россия кредит оешмаларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм шартларда конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алу өлешендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле акты үз көченә кергән көннән соң 90 көн узгач кулланыла. Күрсәтелгән срокка кадәр "Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында" 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) 5 статьясындагы $6^2$ өлешендә күрсәтелгән конкурсны үткәрү тәртибе һәм аның шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының "а" пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацлары, 3 пункт, 7 пунктындагы "а" пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацлары, "г" пунктчасы, "д" пунктчасы 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законның үтәлешен тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 5 декабре
№ 102-ТРЗ